| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ БОЛЬШЕНУРКЕЕВСКГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР НӨРКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ<br>2025 елның 18 июне | КАРАР<br>№ 116 |

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3,7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының бишенче чакырылыш Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Сарман» газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
Совет рәисе урынбасары Х.Ш.Шайхеразиев